КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 21 апрель г.Казань № 253

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында» 2024 ел, 12 сентябрь, 777 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында» 2024 ел, 12 сентябрь, 777 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар

ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарда «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар» юлының «2025 ел» графасында «69,43» саннарын «74,77» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтендә «Башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәте» юлының «2025 ел» графасында «69,43» саннарын «74,77» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин